ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 138-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы <u>КАРАР БИРӘ:</u>

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Р.Р. Фазылов һәм А.А. Чубаров тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 138-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 519-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Р.Р. Фазылов һәм
А.А. Чубаров тарафыннан
кертелә

**«Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» 2020 елның 13 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 26 (I өлеш); 2022, 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) 2 пунктта «хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә килеп чыга торган хәвефләр» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булу чорында, сугыш вакытында килеп чыга торган хәвеф-хәтәр (алга таба – хәвеф-хәтәр)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) халыкны эвакуацияләү, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне яклау;»;

в) 6 пунктта «хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә халык өчен куркыныч туган» сүзләрен «хәвеф-хәтәр барлыкка килгән» сүзләренә алмаштырырга;

г) 7 пунктта «хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә» сүзләрен «хәвеф-хәтәр барлыкка килү аркасында» сүзләренә алмаштырырга;

д) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) хәвеф-хәтәр барлыкка килү аркасында килеп чыккан янгыннарга каршы көрәшү;»;

е) 11 пунктта «хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә» сүзләрен «хәвеф-хәтәр барлыкка килү аркасында» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 14 пунктта «хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә» сүзләрен «хәвеф-хәтәр барлыкка килгәндә» сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле 2[1] пункт өстәргә:

«2[1]) гражданнар оборонасы өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы җитәкчесе тәкъдиме буенча тулы күләмдә яисә өлешчә Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планын гамәлгә кертә;»;

3) 7статьяның 1 өлешендә:

а) 2 пунктта «, коткару хезмәтләрен төзи» сүзләрен өстәргә;

б) 5 пунктта «халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне имин районнарга эвакуацияләүне әзерләү, аларны урнаштыру» сүзләрен «халыкны эвакуацияләүне әзерләү, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне яклауга әзерләү һәм яклау» сүзләренә алмаштырырга;

4) 10 статьяның 2 пунктында «территориаль органнар – Россия Федерациясе субъектлары буенча гражданнар оборонасы мәсьәләләрен һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләрен хәл итүгә вәкаләтле органнар» сүзләрен «гражданнар оборонасы өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органнары» сүзләренә алмаштырырга;

5) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. **Федераль башкарма хакимият органнарының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм гражданнар оборонасы белән идарә итү органнары һәм гражданнар оборонасы көчләре эшчәнлеген координацияләү**

Федераль башкарма хакимият органнарының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм гражданнар оборонасы белән идарә итү органнары һәм гражданнар оборонасы көчләре эшчәнлеген координацияләү Федераль законда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

6) 12 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Федераль закон нигезендә гражданнар оборонасы буенча республика дәрәҗәсендәге аерым чараларны финанс белән тәэмин итү тәртибе, шулай ук мондый чараларның исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 20 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) федераль законнарга кертелгән үзгәрешләр нигезендә Татарстан Республикасының норматив хокукый базасын үстерү максатларында эшләнде.

Гражданнар оборонасын махсус хәрби операция тәҗрибәсен исәпкә алып камилләштерү, карарлар кабул итү тизлеген арттыру, гражданнар оборонасы белән идарә итү буенча Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы вәкаләтләрен көчәйтү максатларында «Гражданнар оборонасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 23 июлендәге 240-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 240-ФЗ номерлы Федераль закон) кабул ителде.

240-ФЗ номерлы Федераль законда төшенчәләр аппаратын бер калыпка китерү максатларында «гражданнар оборонасы», «гражданнар оборонасы белән идарә итү» төшенчәләренә төзәтмәләр кертелде, ә «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булу чорында, сугыш вакытында килеп чыга торган хәвеф-хәтәр» төшенчәсенә граждан обороначы чаралары үткәрелә торган барлык төр хәвеф-хәтәр һәм куркыныч янаулар берләштерелде.

Төшенчәләр аппараты төгәлләштерелүне исәпкә алып, гражданнар оборонасы бурычлары исемлеге дә төзәтелде.

240-ФЗ номерлы Федераль законда шулай ук Россия Федерациясенең аерым субъектларында гражданнар оборонасын алып бару Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары гражданнар оборонасы өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы җитәкчесе тәкъдиме буенча тулы күләмдә яисә өлешчә тиешле Россия Федерациясе субъекты гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планнарын гамәлгә керткән вакыттан башлана.

Федераль башкарма хакимият органнары һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары гражданнар оборонасы буенча чаралар үткәргәндә күрсәтелгән органнарның эшчәнлеген координацияләү мәсьәләләрен билгеләү Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча хөкүмәт комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар гражданнар оборонасы буенча чаралар үткәргәндә күрсәтелгән органнарның һәм оешмаларның эшчәнлеген координацияләүне Россия Федерациясе субъектларының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Федераль законнардагы үзгәрешләрне исәпкә алып, закон проектында «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» 2020 елның 13 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына охшаш үзгәрешләрне кертү тәкъдим ителә.

Закон проекты ике статьядан гыйбарәт. Закон проектының 2 статьясында аның 2026 елның 20 гыйнварыннан үз көченә керүе каралган.

**«Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы закон актларын һәм норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чаралар бүлеп бүлеп бирүне таләп итми.